# ТАТАР ХАЛКЫНЫҢ МАТДИ МӘДӘНИЯТЕН ЧАГЫЛДЫРГАН ЛЕКСИК БЕРӘМЛЕКЛӘР БУЛАРАК АЗЫК-ТӨЛЕК АТАМАЛАРЫ

*Нурмөхәммәтова Р.С., ф.ф.к., доцент*

Хәзерге вакытта тел белемендә тел һәм мәдәният нисбәтен милли үзенчәлекләргә бәйләп карауга көннән-көн зуррак игътибар бирелә. Тел – милли мәдәният формалашуда иң мөһим элемент. Тел – шушы телдә сөйләшүче халыкның милли мәдәнияте хәзинәсе. Аерым бер этносның дөньяны танып-белү үзенчәлекләре, милләтнең матди һәм рухи мәдәниятенә караган сыйфатлар телнең лексик дәрәҗәсендәге берәмлекләргә туплана.

Матди мәдәниятне чагылдырган предметлар, нигездә, көндәлек тормыш-көнкүреш өлкәсендә кулланыла. Көнкүреш лексикасы һәм матди мәдәният күренешләрен чагылдырган сүзләр күпмедер дәрәҗәдә туры килә. Алар матди мәдәниятнең төп өлешләре буларак карала. Теләсә кайсы телнең сүзлек составында әлеге халыкның тормыш-көнкүрешенә караган лексика шактый зур урын били. Нәкь менә аларда яшәү өчен иң мөһим предметлар һәм күренешләр ачык чагылыш таба. Көндәлек кирәк-яраклар, ашамлыклар, кием, торак матди мәдәниятне өйрәнүдә төп чыганак объектларны тәшкил итә.

Телнең лексик байлыгын тулаем алып тикшерү гаять кыен һәм мөмкин дә түгел. Чөнки лексика телнең иң хәрәкәтчән өлкәләреннән санала, нәкь менә ул “чорлар бәйләнешен” тәэмин итә: анда җәмгыятьнең элеккеге һәм хәзерге матди һәм рухи мәдәнияте турында мәгълүмат табарга була. Телнең аерым бер үсеш чорындагы сүзләрен күпмедер дәрәҗәдә тотрыклы хәлендә өйрәнү өчен сүзлекләр ышанычлы кулланма булып хезмәт итә.

Телнең лексикасындагы иң актив сүзләрне, гадәттә, тәрҗемәле сүзлекләр туплап бирә, чөнки ике телдә аралашуның төп шарты – телнең төп сүзлек запасыннан хәбәрдар булу. Гәрчә мондый сүзлекләр телнең лексик байлыгын тулаем чагылдыра алмаса да, тикшерелә торган лексик-тематик төркемнең һичьюгы бер фрагментын күзаллау өчен без XX гасыр ахырында чыккан “Татарча-русча сүзлек”кә мөрәҗәгать иттек.

Азык-төлек халыкның иң борынгы матди мәдәният элементларыннан берсе саналырга хаклы. Аларда кешеләрнең күп гасырлык гореф-гадәтләре аеруча ачык чагылыш таба. Татар милли ризыклары үзләренең төрлелеге, бизәлеше һәм тәме ягыннан дан тота. Татар халкының кулинария сәнгате тарихы белән бик еракларга барып тоташа. Күп еллар дәвамында формалашкан милли татар ризыклары бүгенге көнгә кадәр үзенчәлекләрен саклап калганнар. Әмма шунысын да әйтергә кирәк: татар милли кухнясы үз этник традицияләре нигезендә генә үсмәгән, аңа күрше халыкларның да йогынтысы булган. Татарлар инде күптәннән *пылау, хәлвә, ширбәт* кебек ризыкларны яратып әзерли. Татарларга рус милли ризыклары да бик иртә үтеп кергән. Шул рәвешчә алар татар халкы табынын төрләндергәннәр, тик аның төп үзенчәлекләре сакланып калган.

Хәзерге вакытта традицион туклану культурасы үткәнгә калып бара. Кешеләр тиз әзерләнә торган ризыкларга өстенлек бирә. Ә милли ризыклар ритуал дәрәҗәсендә әзерләүне, күп вакытны таләп итә. Шул сәбәпле өйдә әзерләнә торган ашамлыкларның үзләре белән аларга бәйле лексик берәмлекләр дә юкка чыгу алдында. Халыкларның этник үзенчәлекләре бетеп барган бүгенге көндә милли ризык атамаларын, аларны әзерләү ысулларын өйрәнү, саклап калу гаять әһәмиятле.

“Азык-төлек” тематик төркеме төрлелеге белән аерылып тора, аның эчендә дә берничә төркемчә бүлеп чыгарырга мөмкин.

1. Азык-төлекне гомумиләштереп атый торган сүзләр: *азык, аш, ашамлык, аш-су, күчтәнәч, нигъмәт, ризык, сый, таба ашы, тәм-том* һ.б. Бу сүзләр арасында бер төркем ризыкларны гына гомумиләштереп атаучылары да бар: *таба ашы* сүзе табада пешерелә торган ашамлыкларны берләштерә, *тәм-том* дигәндә, нигәдер, баллы ризыклар күз алдына килә. Кунакка барганда теләсә нинди ризыкны *күчтәнәч*кә алырга була, тик шулай да, гадәттә, кешегә чәй ризыклары алып бару кабул ителгән. “Ачык чырай – такта чәй” ди бит татар халкы. Өйгә килгән кешене чәй эчермичә җибәрү татарларда гайре табигый хәл санала, шуңа да алып барган күчтәнәчләр бу табында бер дә артык булмый.

*Сый* сүзе дә гадәти генә ризыкларны атамый, ә кунак табынына куела торганнарын белдерә.

2. Шулпалар һәм аларны атый торган сүзләр: *борщ, пилмән, салма, токмач, умач, чумар, шулпа, щи, өйрә* һ.б. Шулпа һәм ашларны татар халкы элек-электән әзерли. Гадәти көннәрдә дә, кунак сыйлаганда да татарлар табынга *шулпа* бирәләр. Авылларда исә ул төп ашамлык булып саналган. Аңа *токмач* салып та, *умач* уып та, *чумар* белән дә, ярма салып *өйрә* итеп тә пешерәләр. *Пилмән* дә шулпасы белән бергә беренче аш итеп бирелә.

3. Итле ризык атамалары: *билдәмә, бишбармак, дерелдәвек, ит, казылык, калҗа, койка, колбаса, котлет, куллама, куырма, кыздырма, кәбаб, сосиска, сукта, сызык, тулма, тутырма, фарш, фрикаделька, эч-бавыр* һ.б. *Ит* татарларның элек-электән яраткан ашы булган. Ит ризыклары, бердән, күчмә тормыш белән яшәгән бабаларыбыздан мирас булып калса, икенчедән ул кырыс табигать шартларында яшәргә җайлашу өчен бик мөһим булган. Иттән аш, шулпа пешергәннәр. Ат итеннән гаять күп төрле ашлар әзерләгәннәр, кайберләрен исә бары тик шул иттән генә пешереп булган. *Куллама* (итле салма), каклаган *казылык* татар ашлары арасында затлы ризыклардан саналган. *Куллама* белән *тулма*ны татар халкы хәзер дә бик яратып ашый. Ат эчәгесеннән *тутырма* – эченә *үпкә-бавыр* белән төрле ярмалар салынган *колбаса* әзерләгәннәр. Хәзер дә башка хайван эчәгесе белән үпкә-бавырдан тутырма (*сукта*) ясыйлар. Итне күп очракта пешереп кулланганнар, бик сирәк очракта, бәйрәм табынына гына кыздырып (*куырма, кыздырма, кәбаб*) биргәннәр. Хайванның баш-аяк итеннән *дерелдәвек, койка* ясаганнар. Кыскасы, татар халкы суелган малның бер генә өлешен дә әрәм итмәгән, аннан тәмле-тәмле ризыклар пешерергә өйрәнгән. Бу ризыклар хәзерге көндә күп кенә халыкларда популяр.

4. Сөт, йомырка ризыкларын белдерә торган сүзләр: *атланмай, брынза, йомырка, йомырка тәбәсе, каймак, катык, кефир, корт, кымыз, кәрчемә, май, сыр, сөзмә, сөт, тура, тәбә, эремчек, әйрән* һ.б. Татар ашлары арасында сөттән әзерләнгән ризыклар элек-электән зур урын алып торган. Ләкин *сөт*не шул

килеш кенә сирәк кулланганнар, аны чәйгә салып эчкәннәр яисә ашамлыкларга салганнар. Сөттән *май* язганнар, *сөзмә, эремчек, катык, каймак, корт (тура)* ясаганнар, катыкны әчетеп *кәрчемә* иткәннәр. Татарлар ясаган *атланмай* бөтен тирә-юньдә дан тоткан. *Йомырка*ны каты итеп тә, чиле-пешле итеп тә пешергәннәр, ашка салганнар, *тәбә* әзерләгәннәр. Сабантуй вакытларында ул традицион ашамлык саналган.

5. Ярма, яшелчә ризыклары атамалары: *боламык, ботка, винегрет, кәлҗемә, пылау, салат* һ.б. Татар кешеләре элек-электән иген иккәннәр, шуңа күрә ярмадан төрле ризыклар, *ботка*лар әзерләгәннәр, бодай, арыш бөртекләрен кыздырып (*куырмач*) ашаганнар. Яшелчәләрне татарлар күп кулланмаган, ә XIX гасыр ахырыннан *бәрәңге* ризыклар арасында төп урынны алган, аның үзен генә дә, төрле ашларга кушып та пешергәннәр, *боламыг*ыннан юка гына кәтлитләр – *кәлҗемә* ясаганнар. Яшелчәләрне күбрәк камыр ризыклары эченә салганнар һәм башка ашамлыклар янына биргәннәр. Бигрәк тә *кабак, чөгендер, суган, кишер, ачы торма* кебек яшелчәләрне күп кулланганнар.

6. Камыр ризыкларын белдерә торган сүзләр: *бавырсак, баранка, белен, булка, бәлеш, бөккән, гөбәдия, дучмак, икмәк, ипи, кабартма, калач,803 кактөш, камыр, катлама, клиндер, коймак, крендель, кызартма, кыстыбый, кәтермәч, көлчә, күмәч, күптермә, ләвәш, паштет, печенье, прәннек, пәрәмәч, сохари, сумса, талкан, тәбикмәк, төш, шәнгә, юка, юача, өчпочмак* һ.б. Татар халкы камыр ашларын электән яратып әзерли. Үзенең формасы, әзерләү рәвеше һәм эченә салына торган әйберләрнең ничек әзерләнүе ягыннан камыр ашлары бик үзенчәлекле. Аларның кайберләрен сыек камырдан (*коймак, белен*), икенчеләрен каты камырдан (*кабартма, паштет, бәлеш* һ.б.), ачы камырдан да, төче камырдан да әзерлиләр. *Гөбәдия, бәлеш, пәрәмәч* һәм хәзерге вакытта киң таралган *өчпочмак* аерым урын алып тора, алар күп вакытта икенче аш итеп бирелә. Кайбер ризыкларның эченә ит белән бәрәңге, кайберләренә ярма, эремчек, корт, җиләк-җимеш салалар. Элек юлга чыгасы кешенең биштәренә *бавырсак, юка, төче күмәч* тыкканнар.

7. Чәй ризыклары: *джем, желе, вафля, зефир, кайнатма, как, карамель, конфет, кош теле, кәләвә, күбек, пудинг, пирожный, урама, повидло, пәхләвә, талкыш кәләвә, торт, хәлвә, чәк-чәк, шикәр, шоколад, ширбәт, әлбә* һ.б. Татар халкы майлар, баллар, татлы әйберләр салып, чәй янына оннан төрле ашамлыклар – *кош теле, чәк-чәк, талкыш кәләвә, пәхләвә, ширбәт* һ.б. әзерли. Бу ризыкларны туй табынына да куялар. Гадәттә бу ашамлыклар табынны бизәп тора, шуңа күрә аларны төрлечә сырлап, матурлап ясыйлар. Элек туй яки башка бәйрәм табынына җиләк-җимештән яки балдан *ширбәт* ясаганнар. Хатын-кызга бала тапканнан соң *әлбә* китергәннәр. Чәйне *шикәр* кабып, *как* салып эчкәннәр.

8. Ризык тәмләткечләр: *желатин, оеткы, серкә, сода, соус, тоз, чүпрә, әчетке* һ.б. Болардан тыш татар кухнясында төрле үләннәр дә тәмләткеч буларак кулланыла (*бөтнек, кerән* һ.б.).

9. Эчемлек атамалары: *аракы, бал, квас, кесәл, компот, коньяк, крем-сода, куас, көмешкә, ликер, спирт, сыра, төнәтмә, чәй* һ.б. Татар халкы *чәй*не бик күптән эчә башлаган. Бу – аның Көнчыгыш илләре белән элек-электән сәүдә элемтәсендә булуы белән аңлатылса кирәк. Сусынны басып, хәл кертеп җибәрә торган *куас*, *әйрән*, төрле файдалы үләннәрдән ясалган *төнәтмәләр, кесәл, компотлар* киң таралган. Шунысы кызганыч: XX гасырда татар халкы табынында исерткеч эчемлекләр дә шактый күренә башлады. Элек күп булса кәрәздән әчетеп хәзерләнгән *бал* эчкән татар халкының соңгы буыны хәзер *аракы, коньяк, ликер, спирт*ны да ят итми башлады.

Телнең сүзлек составы җәмгыятьтәге үзгәрешләргә гаять сизгер. Теге яки бу күренешләрнең, предметларның кулланылыштан төшеп калуы яки, киресенчә, пәйда булуы телдә дә үзгәрешләр китереп чыгара. Теге яки бу халыктан төрле милли ризыклар кабул итү татар теленең сүзлек запасында да билгеле бер күләмдә үзгәрешләр белән сыйфатлана. Төрле милләт кешеләренең бер-берсе белән тыгыз аралашып яшәве, халыкларның миграция нәтиҗәсе буларак телләрнең лексикасында да, халыкларның тормыш-көнкүрешендә дә охшашлыклар барлыкка килә. Әмма телнең лексикасында бер төркем сүзләр

гасырлар буена кулланылышта калалар, чөнки алар тормыш итү өчен иң мөһим, беркайчан да әһәмиятен югалтмый торган төшенчә-күренешләрне атыйлар. Бу хезмәттә без күбрәк әнә шул төркем сүзләргә күбрәк игътибар бирергә тырыштык.

Әдәбият

Ахметьянов Р.Г. Общая лексика материальной культуры народов Среднего Поволжья. - М.: Наука, 1989.

Замалетдинов Р.Р. Теоретические и прикладные аспекты татарской лингвокультурологии. – Казань: Мәгариф, 2009.

Юсупова А.Ш. Двуязычная лексикография татарского языка XIX века. – Казань: Изд-во Казанск. гос. ун-та, 2008.

Чыганак

Татарча-русча сүзлек. 3 нче басма. Проф. Ф.А.Ганиев редакциясендә. – Казан: Татарстан китап нәшрияты, 1998. – 462 б.